Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл Советы
КАРАРЫ

11 декабрь 2020 ел № 9

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл Советының 2016 елның 27 декабрендәге 32 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына электрон рәвештә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә вазыйфаи затларның аерым категорияләренең катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 7 маендагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 21 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Бишмунча авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл Советының 2016 елның 27 декабрендәге 32 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең 2017 елның 20 сентябрендәге 39 номерлы, 2018 елның 17 июлендәге 55 номерлы, 2019 елның 06 маендагы 74 номерлы, 2020 елның 03мартындагы 88 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 карарга кушымтада :

1.1.1 4.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә сыйныф чинын бирү турындагы белешмәләр муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә һәм хезмәт кенәгәсенә (булган очракта) кертелә. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы мәгълүмат аның хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләргә кертелә.»;

1.1.2 «Муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр» 6 бүлегендә түбәндәге эчтәлекле 6.3 пункт өстәргә:

«6.3 Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында аларның тиешле вазыйфасын биләгән чорында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

1.1.3 7 бүлекнең 7.1 пункты 1 пунктчасы «б» абзацында «Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясы» сүзләренә алмаштырырга»;

1.1.4 9 бүлекнең 9.3 пункты 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

1.1.5 9 бүлекнең 9.3 пункты 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклар керми;»;

1.1.6 11 бүлекнең 11.9 пункты «г» пунктчасын икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

1.1.7 18 бүлекнең 18.1 пункты 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;»;

1.1.8 18 бүлекнең 18.2 пункты 11 пунктчасы 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә гражданның хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (элек хезмәт (хезмәт) эшчәнлеге башкарылмаган очраклардан тыш);».

2. Әлеге карарны Бишмунча авылы, Совет урамы, 57 нче а йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга урамы, 26 а йорт, Бакчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1 йорт, Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Бишмунча авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы Р.Г.Фазлыев